

28 январьда Темников районы Аксел авылында “За-валенки” VI тобәкара фольклор фестивале чын-чынлап халык бәйрәме буларак данга иреште һәм кvпмилләтле халкыбызнын берләшкәнен, vз гореф-гадәтләре белән данлы булуын тагын бер кат исбатлады!
Фестивальнен барлыкка килv тарихы нәкъ менә шушы авылда башлана, чонки бире дә кvптәннән буыннан - буынга киез итекләр, борынгы кышкы аяк киемен сарык йонынннан ясаганнар.
Ел саен бирегә республикабызнын кvрше районнарыннан гына тvгел, Россиянен ерак тобәкләреннән, мә-сәлән, Чуашстаннан да киез итекләр житештерvчеләр килә.      Аксел авылынын Базарлы мәй-данына районнын авыл жирлекләре вәкилләре милли ризыклар һәм декоратив-гамәли сәнгать эшлән-мәләре кvргәзмә-дегустациясен жә-елдергәннәр.
Декоратив - гамәли сәнгати киез итекләр генә тvгел, товар житештерvчеләр киштәләрендә ин кирәкле товарлар да иде. Бу урында татарларыбыз да лаеклы урын алды: казы-колбасалары белән бергә, татар халык ашларыннан авыз итәргә, сатып алырга момкин иде.
Бәйрәмнен топ мәйданчыгында - концерт барды! Татар жырларыбыз мәйданны янгыратты. Ин активлар арасында Тархан, Караево, Митрял, Аксел һәм башка татар авыл клублары һәм китапханә хезмәткәрләре иде. Бәйрәмгә килvчеләрнен кvбесе дәртле койләр астында бер урында тора алмады. Алар жырладылар, биеделәр, спорт ярышларында һәм конкурсларда катнаштылар. Фотодагы Митрял авылынын “Сандугачлар” ансамбле (житәкчесе Зәйнәб Утешева) Темников районы администрациясенен Рәхмәте-Благодарность белән бәйрәмнән кайттылар.

**Н.ХӘЛИЛ**